ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТРОИЦКО- УРАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422657, с. Троицкий Урай,
ул. Прикамская, дом 9

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТРОИЦКИЙ УРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422657, Троицкий Урай авылы,
Чулман буе урамы, 9 нче йорт

Тел.: (84361)24320, факс: (84361) 24320, e-mail: Tur.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.09.2019 Троицкий Урай авылы №12

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 14 июнендәге “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 9 номерлы карары белән расланган күчемсез мөлкәт объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге “Федераль мәгълүмати адреслы система хакында һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында” 227-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 14 июнендәге “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 9 номерлы карары белән расланган күчемсез мөлкәт объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 14 июнендәге 9 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 кушымтаның 1.5 пунктында:

а) “адресация объекты – бер яки берничә күчемсез мөлкәт объекты, шул исәптән җир кишәрлекләре яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресларны бирү, үзгәртү, юкка чыгару кагыйдәләре белән каралган очракта, адрес бирелә торган башка объект;” җөмләсен “адресация объекты – капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;” җөмләсе белән алмаштырырга;

б) “”планлаштыру структурасы элементы" – зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;” җөмләсен “планлаштыру структурасы элементы – җирлек, шәһәр округы яисә муниципаль районның авылара территориясенең бер өлеше ( квартал, микрорайон, район һәм башка шундый элементлар). Планлаштыру структурасы элементларының төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.” җөмләсе белән алмаштырырга;

в) “адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структурлаштырылган һәм шул исәптән планлаштыру структурасы элементының (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементының исемен, шулай ук адреслау объектын идентификацияләү (тәңгәлләштерү) мөмкинлеген бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы тамгаланышын үз эченә алган адресация объектының урнашу урынының тасвирламасы” җөмләсен “адрес – Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм шул исәптән урам-юл челтәре элементының исемен һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының исемен (кирәк булганда), шулай ук адресация объектын идентификацияләү (тәңгәлләштерү) мөмкинлеген бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы тамгаланышын үз эченә алган адрес объектының урнашкан урынын тасвирлау” җөмләсе белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Троицкий Урай авылы, Чулман буе урамы, 9 йорт; Гремячка авылы, Александров урамы, 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий Урай авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сафин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТРОИЦКО-УРАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ